КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 25 май г.Казань № 396

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының санитария-эпидемияләргә каршы комиссиясе составы турында» 2013 ел, 17 июнь, 412 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының санитария-эпидемияләргә каршы комиссиясе составына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының санитария-эпидемияләргә каршы комиссиясе составы турында» 2013 ел, 17 июнь, 412 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 9 август, 555 нче; 2013 ел, 30 сентябрь, 703 нче; 2015 ел, 17 март, 158 нче; 2016 ел, 22 декабрь, 972 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының санитария-эпидемияләргә каршы комиссиясе составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

комиссия составыннан Г.Ю.Вафинны, П.Л.Анисимовны, А.В.Антипинны, А.Г.Бабаеваны, З.Ю.Гарәфиевне, А.И.Закировны, Р.С.Сафиуллинны чыгарырга;

комиссия составына түбәндәгеләрне кертергә:

Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, комиссия рәисе Ләйлә Ринат кызы Фазлыеваны;

Татарстан Республикасының сәламәтлек саклау министры, комиссия рәисе урынбасары Марат Наил улы Садыйковны;

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының полиция башлыгы урынбасары Марат Илдар улы Айдаровны (килешү буенча);

Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты рәисе Федор Сергеевич Батковны;

Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе Айрат Ринат улы Зариповны;

Татарстан Республикасының урман хуҗалыгы министры Равил Әфраим улы Кузюровны;

Татарстан Республикасының сәнәгать һәм сәүдә министры урынбасары Герман Янович Лернерны;

Россия Федерациясе Федераль иминлек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе бүлеге башлыгы Рөстәм Фәрид улы Мөбарәкшинны (килешү буенча);

Татарстан Республикасының экология һәм табигый байлыклар министры Александр Валерьевич Шадриковны;

Сәламәтлек саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органы җитәкчесе вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Любовь Николаевна Шәйхетдинованы (килешү буенча).

Марина Александровна Патяшина вазыйфасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе җитәкчесе (килешү буенча)».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин